ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КУЧУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӨЧЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.02.2021 Түбән Көчек авылы № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 09 июлендәге 16 номерлы карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, утыртуга яисә ябалдашларын кисүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Салым бурычын каплау эшен оештыру турында» 2020 елның 30 декабрендәге 16-54/16211 номерлы мәгълүмат хатын, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «МНПАга үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 13 гыйнварындагы 09/13-09/49 номерлы запросын, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында норма кертергә кирәк булган муниципаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен һәм процедурасын регламентлаучы муниципаль норматив хокукый актлар исемлеген җибәрү турында» 2021 елның 19 гыйнварындагы 11/13-09/140 номерлы мәгълүмат хатын, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Җир эшләрен җитештерүгә ордер (рөхсәт) бирү һәм агач һәм куакларны кисүгә, утыртуга яисә ябалдашларын кисүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча МНПАга үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 22 гыйнварындагы 11/13-09/236 номерлы мәгълүмат хатын, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Салым бурычын каплау эшен оештыру турында» 2021 елның 26 гыйнварындагы 05-51/399 номерлы запросын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Көчек авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 09 июлендәге 16 номерлы карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, утыртуга яисә ябалдашларын кисүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында 2 бүлегендәге 2.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2 абзац өстәргә:

«2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына - Россия Федерациясе Федераль салым хезмәте бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр авария хәлендәге хәлләргә бәйле очраклар өчен бирелми (билгеләнә).»;

- «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында 2 бүлегендәге 2.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 абзац өстәргә:

«4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр авария хәлендәге хәлләргә бәйле очраклар өчен бирелми (билгеләнә).»;

- 3 бүлегенең 3.4.1 пунктындагы 3.4.1 пунктчасында беренче абзацка түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«һәм законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурыч булу (булмау) турында белешмәләр.

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр авария хәлендәге хәлләргә бәйле очраклар өчен бирелми (билгеләнә).».

2. Әлеге карарны Көчек авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе Р.Ә.НУРМӨХӘММӘТОВ

Исполнительный комитет Кучуковского сельского поселения
Көчек авыл җирлеге башкарма комитеты
ИНН 1601006009